5) оештырылган белем бирү эшчәнлеге дәвамында балаларның кызыксынуын саклап кала белү (0-5 балл);

6) төркемдәге балалар белән үзара бәйләнеш стиленең адекватлыгы (0-5 балл);

7) төркемдәге балаларның үзара бәйләнешен һәм хезмәттәшлеген оештыру (0-5 балл);

8) оештырылган белем бирү эшчәнлегендә балаларның активлыгын һәм инициативалылыгын исәпкә алу һәм ярдәм күрсәтү (0-5 балл);

9) гомуми культура (0-5 балл);

10) санитария-эпидемиология нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килү (0-5 балл);

11) үткәрелгән ачык рәвештә оештырылган белем бирү эшчәнлеге буенча үзеңә-үзен ясаган анализның эчтәлекле, объектив булуы (0-5 балл).

20) Ачык рәвештә оештырылган белем бирү эшчәнлеген күрсәтү нәтиҗәләре буенча икенче этапта иң күп балл җыйган 9 конкурста катнашучы билгеләнә. Алар конкурсның финалистлары була.

21) Конкурсның өченче этап (финал) программасы «Минем уңышлы проект» доклад-презентациясеннән, «Мастер-класс» һәм түгәрәк өстәлдән тора.

22) Катнашучының проектлар методын практикада куллануын чагылдыра торган «Минем уңышлы проект» доклад-презентациясе проект эшчәнлегенең барлык субъектлары өчен мөһим булган максатның тасвирламасын, аңа ирешүнең килешенгән эш итүләрен һәм алымнарын, тәрбияләнүчеләргә белем бирү бурычын (проблеманы) мөстәкыйль чишәргә мөмкинлек тәэмин итүче нәтиҗәләрне, аларның төрле эшчәнлектә яңа тәҗрибә алуын үз эченә ала. Регламент: 10 минутка кадәр, чыгышлар – 7 минутка кадәр, оештыру комитеты сорауларына җаваплар – 3 минутка кадәр.

23) «Минем уңышлы проект» доклад-презентациясен бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) проектның мәктәпкәчә белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандартына, мәктәпкәчә белем бирүне үстерүнең актуаль юнәлешләренә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның кызыксынуларына һәм яшенә туры килүе (0-10 балл);

2) проектта катнашучыларның (тәрбияләнүчеләрнең, ата-аналарның (законлы вәкаләтлеләрнең), башка балачак социаль институтлары вәкилләренең максатчан аудиториясен сайлауның нигезле булуы (0-10 балл);

3) куелган максатның һәм ирешелгән нәтиҗәләрнең мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсеше, аларның төрле эшчәнлектә яңа тәҗрибә алулары өчен әһәмияте (0-10 балл);

4) проектны башкару барышында субъектларның (белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылырның) үзара бәйләнешен һәм проект эшчәнлегенең ирешелгән нәтиҗәләрен демонстрацияли белү (0-10 балл);

5) проектны башка педагогия хезмәткәрләре тарафыннан тормышка ашыру мөмкинлеге (0-10 балл);

6) проектның нәтиҗәлелегенә (уңышлы булуына) үзеңә-үзең бәя бирү (0-10 балл);

7) мәгълүматны тәкъдим итүнең оешканлыгы һәм культурасы (0-10 балл).

24. «Мастер-класс» халык алдында мәктәпкәчә белем бирүне үстерүнең заманча технологияләрен чагылдыручы конкрет методик алымны, методны, тәрбияләү, белем бирү, үстерү һәм сәламәтләндерү технологиясен демонстрацияли торган чыгыш ясаудан гыйбарәт. Тема конкурсант тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә (регламент – 15 минутка кадәр).

25. «Мастер-класс»ны бәяләү критерийлары:

1) материалның мәктәпкәчә белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандарты логикасына туры килүе, шул исәптән биш белем бирү өлкәсенең берсен исәпкә алып (социаль-коммуникатив, танып белү, сөйләм, сәнгати-эстетик, физик үсеш) (0-5 балл);

2) эчтәлек һәм форманың яңалыгы, тирәнлеге һәм оригинальлеге (0-5 балл);

